АКЦИОНЕРНОЕ ОБЩЕСТВО
“ТАТМЕДИА”
РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛА
«КАЗАН УТЛАРЫ»
г. Казан, 420066, ул. Декабристов., д. 2, а/я 49
Тел.: (843) 222-05-50 доб. 1618
Факс.: (843) 222-09-83 доб.1612
e-mail: kazanutlari@yandex.ru

“ТАТМЕДИА”
АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ
«КАЗАН УТЛАРЫ»
ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ
Казан шәһ., 420066, Декабристлар ур., 2, а/я 49
Тел.: (843) 222-05-50 доб. 1618
Факс.: (843) 222-09-83 доб.1612
e-mail: kazanutlari@yandex.ru

№ 02-19 14.01.2019

ТР мәгариф һәм фән министрының
беренче урынбасары
И.Г. Һадиуллинга

Хөрмәтле Илсур Гәрәй улы!

ТАССР һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы оешуга 100 ел тулу уңаеннан Республикабызда сәламәтлек сагында торучыларның хезмәтенә әдәбиятыбыз аша игътибар юнәлтү, татар әдәбиятын сәламәтлек саклау, медицина өлкәсенә караган әсәрләр белән баету, иҗатта яңа авторлар табу, алар белән даими хезмәттәшлек итү максатында «ТАТМЕДИА» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Казан утлары» журналы редакциясе, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә, медицина хезмәткәрләре турында **«Шифалы куллар»** дигән ачык **әдәби конкурс** игълан итә. Әлеге бәйгедә мәктәп укучыларын катнаштыру да күздә тотыла. Алар “шигърият” номинациясендә көч сынашачак. I урын алучыга 15000 сум, II урын иясенә 12000 сум, III урын яулаучыга 8000 сум, һәм 5000 сумлык биш кызыксындыру премиясе каралган. Мәктәп укучыларының шигырьләре журналыбызның интернет сайтында басылып барачак.

Шул уңайдан, Сездән бу әдәби конкурс турындагы мәгълүматны республикабыз мәктәпләрендә һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларында таратуда ярдәм итүегезне сорыйбыз.

Конкурс шартлары тулырак журналыбыз сайтында:
http://kazanutlary.ru/news/byge/i-yakhshy-dbi-ocherk

Электрон адрес: kazanutlari@yandex.ru.

Элемтәләр өчен телефон: 8(843) 222-09-83(өстәмә 1616);
8-917-915-88-73 – Рамил Ханнанов; 8-917-230-89-93 Айсылу Имамиева

Ихтирам белән,
Җитәкче – баш мөхәррир **Р.Г. Галиуллин**